Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XX-1**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 24 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге XI-1 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3.Дәүләт теркәве узганнан соң карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырып бастырырга.

4. Әлеге карар “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 90 маддәсендәге 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 24 июлендәге
XX-1номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 маддәнең 1 өлешендә:

а) 14 пункттагы «каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру» сүзләрен «каникул чорында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә, аларның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, чараларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

б) 39 пункттагы «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 маддәнең 1 өлешендәге 25 пунктындагы «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон сүзләренә алмаштырырга;

3) 17 маддәнең 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) район Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, әлеге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Конституциясе яисә законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан гайре;»;

4) түбәндәге эчтәлекле 26.1 маддәсен өстәргә:

« 26.1.маддә. Район Советында фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре

1. Сәяси партияләр (аларның региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлекләре составында сайланган район Советы депутатлары депутат берләшмәләренә (фракцияләргә) (алга таба - фракциягә) керә, моңа әлеге маддәнең 6 өлешендә каралган очрак керми. Фракция кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган барлык депутатларны (депутатны) үз эченә ала. Фракциядә шулай ук бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар да, әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партия (аның региональ

бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчәсе) кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар (депутат) керә ала.

2. Фракцияләр эшчәнлеге тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм район Советы регламенты белән билгеләнә.

3. Фракциянең тулы исеме - кандидатлар исемлеге составында тиешле депутатлар сайланган сәяси партия уставында күрсәтелгән исем (аталышы). Фракция фракция турындагы Нигезләмәдә аның тулы исеменә туры килә торган кыскча исемле булырга хокуклы.

4. Фракцияләр район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәчел (хәбәрнамә җибәрелеп) теркәлергә тиеш.

Яңа теркәлгән фракция турында белешмәләр, шулай ук күрсәтелгән фракциягә керүче (кергән) депутат (депутат) турында белешмәләр район Советы фракциясе теркәлгәннән соң беренче утырышта игълан ителә.

5. Фракциянең эчке эшчәнлеге аның тарафыннан оешкан җыелышында тиешле кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән расланган фракция турындагы нигезләмә нигезендә мөстәкыйль рәвештә оештырыла.

6. Сәяси партия эшчәнлеген бетерү яки үзгәртеп оештыру сәбәпле аның район Советында фракциясе эшчәнлеге туктатылган очракта, шулай ук әлеге фракциядә депутатлар әгъзалыгы тиешле язмадагы юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән көннән туктатыла.

7. Сәяси партия (аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчәсе) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутат әлеге мадденең 1 өлеше нигезендә торган фракциядән чыгарга хокуклы түгел. Күрсәтелгән депутат ул сайланган кандидатлар исемлеге составында шул сәяси партия әгъзасы була ала.

8. Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат яки әлеге мадденең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм фракциягә керүче депутат бары тик ул фракциясенә кергән сәяси партия әгъзасы була ала.

9. Әлеге мадденең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм район Советында үз фракциясе булган сәяси партиягә кергән Депутат әлеге фракциягә керә һәм аннан чыга алмый.

10.Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат аннан хәбәрнамәчел тәртиптә чыга ала.

Депутатның фракциядә әгъза булып торуын туктату турындагы мәгълүмат район Советы утырышында игълан ителә.

11. Әлеге мадденең 7 - 9 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәмәү депутат вәкаләтләрен туктатуга китерә.

12. Кандидатлар исемлеге составында сайланган район Советы депутатларының (депутатының) фракциясенә керүче вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса, анда шундый исемлек составында сайланган депутатлар (депутат) булмавына китергән очракта, күрсәтелгән фракциянең эшчәнлеге район Советында туктатыла. Бер үк вакытта бермандатлы яисә күпмандатлы

сайлау округлары буенча сайланган депутатлар һәм әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партия (аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчәсе) кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар составындагы шундый фракциядә әгъзалык туктатыла.

13. Әлеге маддәнең 6, 12 өлешләре нигезендә фракция эшчәнлеген туктату турындагы мәгълүмат район Советы фракциясе эшчәнлеге туктатылганнан соң беренче утырышта игълан ителә.

14. Бер мандатлы яисә күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар һәм фракциягә кермәгән, әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партия (аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчәсе) кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән депутат берләшмәләрен фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре төзергә мөмкин. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре партия, территориаль, һөнәри яисә башка билгеләр буенча төзелә. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе район Советы регламенты белән билгеләнә.

15. Бөтен депутат мандатларын бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар биләгән район Советы депутатлары фракция булмаган депутат берләшмәләре төзи ала. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре партия, территориаль, һөнәри яисә башка билгеләр буенча төзелә. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе район Советы регламенты белән билгеләнә.

16. Район Советы депутаты бары тик бер депутат берләшмәсендә генә торырга хокуклы.»;

5) 27 маддәдә:

а) 7 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 9-11 өлешләрне өстәргә:

«9. Район Советы депутаты тарафыннан коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары буенча Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

10. Әлеге маддәнең 7 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон  белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда Татарстан Республикасы Президенты район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки күрсәтелгән затларга карата башка төр җаваплылык чарасын куллану турында гариза (белдерү) белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле район Советына мөрәҗәгать итә яки судка.

11. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен тапшырыла.»;

6) 28 маддәгә түбәндәге эчтәлектәге 4-7 өлешләрне өстәргә:

«4. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды территорияләрендә, аларны үткәрү тормыш-көнкүреш объектлары эшчәнлеген бозуга, транспорт һәм социаль инфраструктура, элемтә, җәяүлеләр һәм (яки) транспорт чаралары хәрәкәтенә комачаулык тудыру яки гражданнарның торак урыннарына яки транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә юл куймауга  китермәслек шарт белән үткәрелә.  Мондый очрашулар турында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны үткәрү датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

5. Район Советы депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар билгели, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен тәгаенли.

6. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

7. Депутатның сайлаучылар белән җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган гавами чара формасында сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә үткәрүгә комачаулык итү Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка  китерә.»;

7) 36 маддәнең  3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты район Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында белдерү (гариза) белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн - әлеге гариза район Советына кергән көн..»;

8) 37 маддәнең 2 өлешендә «хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 39 маддәдә:

а) 4 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итү белән коммерциягә нигезләнмәгән оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси фирка, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында яки корылтаенда (конференциясендә) катнашудан тыш);;»;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Район Башлыгы 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны (вазыйфаларны) башкарырга тиеш.».»;

в) түбәндәге эчтәлектәге 6 өлешне өстәргә:

«6. Район Башлыгы 2015 елның 13 июлендәге “Дәүләт-хосусый партнерлык, Россия Федерациясендә муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль-шәхси партнерлык өлкәсендә гавами партнер буларак район исеменнән чыгыш ясый.».»;

10) 40 маддәнең 1 өлешендә:

а) 15 пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 16 һәм 17 пунктларны өстәргә:

«16) муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итә;

17) 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсендәге 2 өлеше нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык

өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы районның җирле үзидарә органын билгели;»;»;

б) 16 пунктны 18 пункт дип санарга;

11) 41 маддәдә:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки суд карары буенча процессуаль мәҗбүри итү чараларын кулланып сак астына алу яки вазыйфадан вакытлыча азат итү рәвешендәге очракларда аның вәкаләтләрен вакытлыча район Башлыгы урынбасары башкара..»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, район Советы тарафыннан үз составыннан сайланучы район Башлыгын сайлау вәкаләтләре шул рәвешле туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Район Советы вәкаләтләре срогы чыкканчы алты айдан кимрәк вакыт калса, район Башлыгын район Советы составыннан сайлау район Советының беренче утырышында башкарыла.»;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Район Советы тарафыннан сайланган район Башлыгы, аның вәкаләтләре район Советының аны отставкага чыгару турындагы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган очракта, күрсәтелгән карарга суд тәртибендә шикаять бирә, район Советы суд карары закон көченә кергәнче район башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуксыз.»;

12) 42 маддәнең 8 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);»;

13) 46 маддәдә:

а) 1 өлешендә:

3 пунктның сигезенче абзацында «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның икенче абзацында «каникуллар вакытында балаларның ялын оештыра» сүзләрен «каникуллар вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра, моңа аларның

тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең 27 пунктында «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлектәге 5 өлешне өстәргә:

«5. Террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә район Башкарма комитеты:

1) террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра;

2) районда терроризмның асылын һәм аның иҗтимагый хәтәрлеген аңлату буенча мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү буенча, шул исәптән мәгълүмат материалларын, матбугат продукциясен тарату, аңлату эшләре алып бару һәм башка чаралар уздыру юлы белән;

3) террорчылыкны профилактикалау чараларында катнаша, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча;

4) муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

5) террорчылыкны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча, шулай ук аның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрә;

6) террорчылыкны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

14) 47 маддәнең 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Район Башкарма комитеты җитәкчесе 2008 елныр 25 декабрендеге "Коррупцияге каршы тору турында" гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга тиеш.»;

15) 51 маддәдә:

а) 1 өлешнең 3 пунктында «2 өлеше» сүзләреннән соң «яисә 3» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлектәге 3-4 өлешләрне өстәргә:

«3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законнар белән билгеләнгән коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (белдерүе) нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин.

4. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары башкара.»;

16) 74 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. гамәлгә куючысы район булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә..»;

17) 88 маддәдә:

а) 3 өлештә икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның шул хакта фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район Уставы проекты буенча, район Советы утырышында аларны карау алдыннан әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы район Советы карарлары әлеге Устав нигезендә ачык тыңлаулар уздырыла, моннан тыш, әлеге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль

законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелә торган очраклардан тыш.»;

18) 89 маддәне түбәндәге эчтәлекле 4-6 өлешләр белән тулыландырырга:

«4. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул рәсмиләштерелә ала:

1)район Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы район Башлыгы кул куйган район Советы карары белән;

2) район Советы тарафыннан кабул ителгән һәм район Башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге хокукый актка район Советының аны кабул итү турындагы карары реквизитлары куела. Район Советының бу карарына күчмә нигезләмәләрне һәм (яки) район Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы нормаларны кертү рөхсәт ителми.

5. Район Уставын Федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актлары белән билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла. Әгәр федераль закон, Татарстан Республикасы законы белән күрсәтелгән срок билгеләнмәгән булса, район Уставын Федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы Законы үз көченә керү датасын, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы Карары проектын халык алдында тыңлауларда фикер алышу зарурлыгын, аның буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу вакытын, район Советы утырышларының вакыт аралыгын исәпкә алып билгеләнә, район Советының мондый карарын Дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) вакыты алты айдан артмаска тиеш.

6. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән яңа редакциядә район Уставына бәян ителми. Бу очракта районның яңа Уставы кабул ителә, ә элегрәк гамәлдәге район Уставы һәм аңа өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар районның яңа Уставы үз көченә кергән көннән үз көчен югалткан дип танылa.»;

19) 90 маддәдә:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Район Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (район уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау вәкаләтләре, вәкаләтләре, вәкаләтләре чоры, тәртибе үзгәртелүдән тыш) район Уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка кул куйган район башлыгының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.»;

б) 4 өлештә «әлеге» сүзен төшереп калдырырга.